МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.03.2023 Казан ш. № 65

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 17 ноябрендәге 359 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының «Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2018 елның 31 июлендәге 34-ОС номерлы боерыгының үз көчен югалтуын тану турында**

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 17 ноябрендәге 359 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Коррупциягә каршы экспертиза вазыйфаи зат тарафыннан «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә

каршы экспертизасы турында» федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгать фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы карары белән, әлеге Тәртип нигезендә расланган тәртиптә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә үткәрелә.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Акт проектына коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез, экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциячел факторлар акт проектын эшләп бетерү стадиясендә аны эшләүче зат тарафыннан бетерелә.

Эшләүче тарафыннан акт проектына аңа коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырылганнан соң үзгәрешләр кертелгән очракта, акт проекты яңадан коррупциягә каршы экспертизага тиешле була.»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып рәсми басылып чыккан Министрлык актлары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары актларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен бердәм төбәк интернет-порталында (алга таба – бердәм төбәк интернет-порталы) билгеләнгән мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырылган Министрлык актлары проектлары, Министрлыкта эшләнгән актларның проектлары тора.»;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Министрлык актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе, акт проекты карау өчен юридик бүлеккә җибәрелгән көнгә туры килә торган эш көне дәвамында, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресын (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтеп, акт проектын алга таба сайтта урнаштыру өчен җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә җибәрә.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру максатларында акт проекты урнаштырылган срок чикләрендә килгән бәяләмә килгән көненнән соңгы эш көненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара электрон документ әйләнешенең бердәм системасында теркәлә.

Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка килгән бәяләмә (алга таба - бәяләмә) карау өчен Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә җибәрелә.»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш итү холкына ия һәм, әлеге Тәртипнең 5.5.1 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, теркәлгән көненнән башлап 15 көнлек срокта Министрлык тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка  нигезләнгән җавап (бәяләмәдә ачыкланган коррупция факторлары турында мәгълүмат яки ачыкланган коррупция факторларын бетерү ысулы турында тәкъдим булмаган очраклардан тыш) җибәрелә, анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләренең исәпкә алынуы һәм (яки) актта яки акт проектында ачыкланган коррупция факторы белән риза булмау сәбәпләре чагылдырыла.»;

түбәндәге эчтәлектәге 5.5.1 пункт белән тулыландырырга:

«5.5.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәге бәяләмәләр каралырга тиеш түгел:

актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар сыйфатында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган формага туры килми.»;

түбәндәге эчтәлектәге 5.5.2 пункт белән тулыландырырга:

«5.5.2. Әлеге Тәртипнең 5.5.1 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта Министрлык мондый бәяләмәне теркәлү көненнән 15 көннән дә соңга калмыйча, сәбәпләрен күрсәтеп, кире кайтара.»;

5.9 пунктны үз көчен югалткан дип танырга:

5.10 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге VI бүлек белән тулыландырырга:

«VI. Актлары проектлары турында иҗтимагый фикер алышу

6.1. Министрлык эшләнә торган актларның проектлары турында иҗтимагый фикер алышуларны тәэмин итә.

6.2. Иҗтимагый фикер алышу максатларында актларның проектлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары актлары проектларын аларга

коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу өчен бердәм төбәк Интернет-порталы итеп билгеләнгән Татарстан Республикасы рәсми порталында (алга таба – Мәгълүмат ресурсы) (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырыла.

6.3. Гражданнарның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына тия торган актларның проектлары иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен Мәгълүмат ресурсында урнаштырыла.

6.4. Иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштырылмый:

дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләре яки конфиденциаль холыклы белешмәләре булган актларның проектлары;

актларны (аларның структур берәмлекләрен) көчен югалткан дип тану турында актларның проектлары;

аларны эшләү буенча Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәсендә билгеләнгән срок иҗтимагый фикер алышуның минималь срогыннан кимрәк (Мәгълүмат ресурсында урнаштырган көннән соң биш эш көненнән кимрәк) булган актларның проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яки чыгымнарына йогынты ясый торган норматив хокукый актлар проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле актларның проектлары;

террорчылыкка, шул исәптән террорчылыкны финанслауга, каршы көрәш чараларын тормышка ашырганда дәүләт хакимияте органнарының эшчәнлеген оештыру, тәэмин итү һәм аларның үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен регламентлый торган актларның проектлары;

Татарстан Республикасы ктларын законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән актларның проектлары;

суд карарларын, прокурор йогынтысы актларын, контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен тормышка ашыру максатларында әзерләнгән актларның проектлары;

дәүләт функцияләре үтәүнең административ регламентлары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында актларның проектлары;

Татарстан Республикасы актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында актларның проектлары.

6.5. Иҗтимагый фикер алышуны тәэмин итү өчен актларның проектлары урнаштырылганда Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчә тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук иҗтимагый фикер алышу срогының башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

6.6. Әзерләүче тарафыннан актларның проектлары хакында иҗтимагый фикер алышу срогы Мәгълүмат ресурсында урнаштырган көненнән башлап биш эш көненнән азрак була алмый.

6.7. Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчә тарафыннан иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча акт проектын өстәмә эшләү турында карар кабул ителгән очракта, өстәмә эшләнгән акт проекты шулай ук иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштырыла.

6.8. Актларның проектларын Мәгълүмат ресурсында урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы, иҗтимагый фикер алышу вакыты тәмамланган көннән алып 30 көн эчендә актны (акт проектын) эшләүче коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру барышында ачыкланган коррупциячел факторлар турында, иҗтимагый фикер алышу барышында килгән тәкъдимнәр турында җыелма мәгълүматны аларны карау нәтиҗәләрен чагылдырып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгать фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын аларның коррупциягә каршы бәйсез экспертизасын уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштыру тәртибенә кушымтадагы форма буенча урнаштыра.

2. Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының «Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2018 елның 31 июлендәге 34-ОС номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**